МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 741/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«10» 06 2025

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында урнашкан «Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү – 1 чират» объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектларын әзерләү турында» 2024 елның 15 июлендәге 206/о номерлы боерыгы нигезендә, 2025 елның 9 гыйнварындагы гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында урнашкан «Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү – 1 чират» объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектынн һәм территорияне ызанлау проектын расларга (кушымтада бирелә).

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең Кама агломерациясен үстерү бүлегенә (В.В.Вельскийга) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь

хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

3. Юридик бүлеккә (Р.И. Кузьминга) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары В.Н. Кудряшев

ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 10 июнендәге 741/о номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында урнашкан «Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү – 1 чират» объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проекты**

| Бүлек номеры | Билгеләнеше | Атамасы | Иск. |
|---|---|---|---|
| 1 | 13194-ППТ-ОЧ-Р1 | 1 бүлек: Территорияне планлаштыру проекты. | |
| | | График өлеше | |
| 2 | 13194-ППТ-ОЧ-Р2 | 2 бүлек: Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | |
| | | объектлар | |
| 3 | 13194-ППТ-МО-Р3 | 3 бүлек: Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | График өлеше | |
| 4 | 13194-ППТ-МО-Р4 | 4 бүлек: Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | Аңлатма язуы | |
| 5 | 13194-ПМТ-ОЧ-Р5 | 5 бүлек: Территорияне ызанлау проекты. | |
| | | График өлеше | |
| 6 | 13194-ПМТ-ОЧ-Р6 | 6 бүлек: Территорияне ызанлау проекты. | |
| | | Текст өлеше | |
| 7 | 13194-ПМТ-МО-Р7 | 7 бүлек: Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | График өлеше | |
| 8 | 13194-ПМТ-МО-Р8 | 8 бүлек: Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | Аңлатма язуы | |

## «Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү – 1 чират» объекты буенча территорияне планлаштыру документлары

## Территорияне планлаштыру проекты
## Төп өлеше

## 1 бүлек: Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше

## Кызыл линияләр сызымының булмавы турында аңлатма язуы

«Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү -1 чират» объекты өчен эшләнә торган проектта кызыл линияләр сызымын әзерләү гамәлдәге кызыл линияләр булмау сәбәпле таләп ителми. Нигезләү – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясындагы 11,12 пунктлары нигезендә проектлана торган объект гомуми файдалану территориясе булып саналмый. Территорияне планлаштыру буенча документация эшләү кысаларында шулай ук кызыл линияләр билгеләү каралмаган.



K-5454



УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

К-5414

| Изм. | Кол.уч. | Лист | №док. | Подп. | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| Разработал | | | | | 02.24 |
| Проверил | | | | | 02.24 |

| Стадия | Лист | Листов |
|---|---|---|
| | 2 | 5 |




Условные обозначения

- Граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- Границы зон планируемого размещения линейных объектов
- Проектируемый нефтепровод
- п 12 — Характерная точка границы зоны планируемого размещения объекта

K-5398

Система координат: МСК-[illegible] (зона 2)

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | [illegible] | | | |
| | | | | | | Обустройство [illegible] месторождения [illegible] | | | |
| Изм. | Кол. уч | Лист | № док. | Подп. | Дата | | | | |
| Разработал | | [illegible] | | | 02.24 | Проект планировки территории. Основная часть | Стадия | Лист | Листов |
| Проверил | | [illegible] | | | 02.24 | | ПП | 3 | 5 |
| | | | | | | Чертеж зон планируемого размещения линейных объектов Масштаб 1:1000 | ООО "[illegible]" | | |



K-5216



## 2 бүлек: Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә

**1. Урнаштыру планлаштырыла торган линия объектларының исеме, төп характеристикалары һәм билгеләнеше**

К-5216 үсеш мәйданчыгыннан алып №5049 кустыннан гамәлдәге нефть үткәргечкә кадәр нефть-газ җыю торбаүткәргече – трассаның озынлыгы 455,03 м, планлаштырылган тирәнлеге 1,68 м, торба материалы – пыяла пластик 81,8.

К-5394 үсеш мәйданчыгыннан алып №5049 кустыннан гамәлдәге нефть үткәргечкә кадәр нефть-газ җыю торбаүткәргече – трассаның озынлыгы 1480,34 м, планлаштырылган тирәнлеге 1,68 м, торба материалы – пыяла пластик 89.

К-5454 үсеш мәйданчыгыннан алып №5199 кустыннан гамәлдәге нефть үткәргечкә кадәр нефть-газ җыю торбаүткәргече – трассаның озынлыгы 395,42 м, планлаштырылган тирәнлеге 1,68 м, торба материалы – пыяла пластик 81,8.

К-5414 үсеш мәйданчыгыннан алып №5049 кустыннан гамәлдәге нефть үткәргечкә кадәр нефть-газ җыю торбаүткәргече – трассаның озынлыгы 226,46 м, планлаштырылган тирәнлеге 1,68 м, торба материалы – пыяла пластик 81,8.

К-5398 үсеш мәйданчыгыннан алып №5142 кустыннан гамәлдәге нефть үткәргечкә кадәр нефть-газ җыю торбаүткәргече – трассаның озынлыгы 422,25 м, планлаштырылган тирәнлеге 1,68 м, торба материалы – пыяла пластик 81,8.

**2. Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге**

Территорияне планлаштыруның әлеге проектында Түбән Кама муниципаль районы чикләрендә Прости авыл җирлеге территориясендәге һәм Түбән Кама шәһәре территориясендәге җирләрдә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә

- гомуми озынлыгы 2979,49 км булган нефть-газ җыю торбаүткәргече.

Эшләр районына иң якын торак пунктлар:

- Прости авылы тикшерү мәйданыннан 1,5 км төньяк-көнчыгыштарак урнашкан;
- Түбән Кама шәһәре тикшерү мәйданыннан 1 км көньяктарак урнашкан;

**3. Линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми)**

**4. Планлаштырыла торган урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрлары**

Территорияне планлаштыру буенча әлеге документациядә планлаштырыла торган зоналар чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын төзү һәм реконструкцияләү каралмаган.

**5. Капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан яклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Нефть-газ җыю торбаүткәргече, тикшерү материалларына караганда, җир асты коммуникацияләрен – түбән көчәнешле кабель, торбаүткәргечләр, электр линияләре, вак таш һәм асфальт юлларны кисеп үтә.

Территорияне планлаштыру проектында нефть үткәргечләр урнаштыруга бәйле рәвештә капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын тискәре йогынтыдан яклау буенча түбәндәге чаралар каралган:

- нефть-газ җыю торбаүткәргечләре гамәлдәге коммуникацияләрдән түбәнрәк салына;
- проектлана торган нефть үткәргечнең гамәлдәге коммуникацияләр һәм автомобиль юлы белән кисешкән урыннарында корыч торбадан саклагыч футлярлар каралган;
- гамәлдәге коммуникацияләр һәм автомобиль промысел юлы белән кисешкән урыннардагы торба үткәргеч участоклары агым эзләгеч белән приборларны эшләтеп җибәрү алдыннан диагностикалауга дучар ителергә тиеш;
- капиталь төзелеш объектларының саклау зоналары территорияләреннән файдалану режимы таләпләрен үтәүне исәпкә алып, төзелеш процессында эшләр башкаруны оештыру.

**6. Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Мәдәни мирас объектларын ачыклау предметына тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан 06.08.2024 ел, №01-04/4331 дәүләт тарихи-мәдәни экспертиза актына бәяләмә бирелде, аның нигезендә тикшерелгән җир кишәрлекләре чикләрендә реестрга кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары яисә объект билгеләренә ия объектлар мәдәни мирас юк.

Проектлана торган эшләр төрле төрдәге һәм чорлардагы мәдәни мирас объектларын җимерү куркынычын тудырмый. Саклау өчен археологик чаралар уздыру яки төзелеш проектын үзгәртү зарурлыгы юк. Тикшерелгән җир кишәрлекләре теләсә нинди хуҗалык эшләрен башкару өчен файдаланылырга мөмкин.

**7. Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

**7.1. Атмосфера һавасын саклау чаралары**

Әйләнә-тирә мохиткә зарарлы матдәләр чыгаруны булдырмау чаралары исемлеге

Атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруны максималь киметү һәм әйләнә-тирә мохитне саклау максатында түбәндәге техник чишелешләр күз алдында тотыла:

- транспортның һәм нефть һәм газ әзерләүнең максималь-герметизацияләнгән басымлы бер торбалы системасы;

- процесс параметрларын автоматлаштыру чаралары, шулай ук аларны бозган очракта блоклау системасы исәбенә билгеләнгән режимда тоту;

- фланец тоташмаларын минималь-кирәкле санда эретеп ябыштыруда эшләнгән нефть транспорты системасы торбаүткәргечләрен файдалану;

- югары басым белән торбаүткәргечләрнең ныклыгына һәм герметиклыгына гидравлик сынау үткәрү;

- җылылык белән эшкәртелгән торбаүткәргечләр һәм детальләр куллану;

- торбаүткәргечләрне һәм җайланмаларны, саклагыч өслекләр һәм электрохимик саклау чараларын кулланып, туфрак туңуыннан комплекслы яклау;

- торбаүткәргечләрнең һәм арматураның җир өсте участокларының тышкы өслеген лак-буяу материаллары белән атмосфера коррозиясеннән саклау;

- транспорт объектларының барлык ачык мәйданчыкларында газ анализаторлары ярдәмендә һава мохите торышын тикшереп тору һәм нефть һәм газ әзерләү;

- вакытлыча файдалануга бирелгән җирләрне рекультивацияләү һәм җирдән файдаланучыларга кире кайтару.

Атмосфера һавасын саклау максатларында түбәндәге шартларны, чараларны һәм эшләрне үтәргә кирәк:

- транспорт чаралары двигательләрен, төзелеш машиналарын һәм механизмнарын атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруның мөмкин булган дәрәҗәсенә мәҗбүри диагностикалау;

- расланган график буенча транспорт чаралары, төзелеш машиналары двигательләрен эшләтеп җибәрү һәм җылыту;

- төнге вакытта техниканы эшли торган двигатель белән калдыруны тыю;

- төзелеш-монтаж эшләре табигатьне саклау законнарының гамәлдәге таләпләре, нормалары катгый үтәлгәндә даими җитештерү, ведомство һәм дәүләт инженер-экология контроле режимнарында гамәлгә ашырылырга тиеш;

-төзелеш-монтаж эшләрен башкарганда кулланыла торган машиналарның двигательләрен һәм механизмнарны көйләү, бу исә эшкәртелгән газлар белән атмосферага зарарлы матдәләр чыгаруны киметә;

- төзелеш өчен бирелгән территория чикләрен мәҗбүри үтәү;

- төзелеш өчен ком җибәрелә торган төзелеш материалларының экологик иминлеге гигиена сертификатлары булган махсуслаштырылган предприятиеләрдән сатып алынырга тиеш;

- юл һәм автотранспорт техникасын билгеләнгән вакытта техник карау, техник хезмәт күрсәтү һәм планлы-кисәтү ремонты үткәрү исәбенә төзек хәлдә тоту;

- төзек булмаган яисә көйләнмәгән двигательле һәм ягулык стандартларына туры килми торган техниканы эксплуатацияләүне тыю;

- калдыкларны һәм төзелеш чүпләрен яндыруны тыю;

- эшләрне этаплап, кыска-кыска юл белән башкару, бу техниканы таратырга ярдәм итә һәм бер үк вакытта атмосфера һавасына йөкләнешне киметә;

- автомашиналарның һәм махсус техниканың агулы һәм төтенле газларын контрольдә тоту;

- ягулык-майлау материаллары таралуны булдырмау;

- коелучан йөк ташучы автосамосваллар һәм борт машиналары алмаштырыла торган махсус тентлар белән җиһазландырылырга тиеш;

- лак-буяу материаллары, сыек нигездәге су үткәрми торган материаллар, мастиклар китерелергә һәм герметик махсус савытта сакланырга тиеш;

- һавадагы зарарлы матдәләрнең микъдарын контрольдә тоту.

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру атмосфера һавасына китерелә торган зыянны минимумга кадәр киметә.

### 7.2. Су объектларыннан рациональ файдалануны һәм саклауны, шулай ук су биологик ресурсларын саклауны тәэмин итә торган чаралар, техник чишелешләр һәм корылмалар

Төзелеш эшләренең җир өсте һәм җир асты су ресурсларына тискәре йогынтысын булдырмау өчен табигатьне саклау чаралары комплексы каралган:

- төзелеш-монтаж эшләрен башкару өчен билгеләнгән чикләрне саклау;

- төзелеш мәйданчыгыннан агып төшүче суларны турыдан-туры урын рельефына оештырылмыйча агызуны тыю;

- эш урыннарын һәм төзелеш мәйданчыкларын коммуналь һәм төзелеш калдыкларын җыю өчен контейнерлар белән тәэмин итү;

- төзелеш чүп-чарларын, коммуналь калдыкларны саклау һәм утильләштерү урыннарына вакытында җыеп чыгару;

- төзелеш мәйданчыгында ягулык саклауны бетерү;

- сыйфат сертификаты булган төзелеш материалларын куллану;

- җир өстендәге һәм кар суларының табигый агымын саклау өчен эшләр тәмамланганнан соң төзелеш полосасын планлаштыру;

- бозылган җирләрне вакытында рекультивацияләү;

- машиналарга һәм механизмнарга техник хезмәт күрсәтү (ягулык салу, юу, ремонт) су саклау зоналарыннан тыш махсус билгеләнгән мәйданчыкларда гына башкарыла.

Нефть промыселы объектларының эшләве авария хәлләре килеп чыгу ихтималына бәйле, нәтиҗәдә өске су объектларына һәм грунт суларына пычраткыч матдәләр җәлеп ителү ихтималы бар. Промысел объектларында авария хәлләре нәтиҗәсендә җир өсте су объектларының һәм грунт суларының пычрануын булдырмау яисә киметү максатында проектта аварияләр килеп чыгу ихтималын киметүгә юнәлдерелгән берничә технологик чишелеш каралган:

- технологик процесс максималь герметизацияләнгән;

- технологик җиһазларны ачык мәйданчыкта урнаштыру, бу шартлау-янгын куркынычы булган зоналар булдыру ихтималын киметә;

- процесс параметрларын автоматлаштыру чаралары, шулай ук аларны бозган очракта блоклау системасы исәбенә билгеләнгән режимда тоту;

- фланец тоташмаларын минималь-кирәкле санда эретеп ябыштыруда эшләнгән

нефть транспорты системасы торбаүткәргечләрен файдалану;

- процесс параметрларын билгеләнгән режимда тоту автоматлаштыру чаралары исәбенә каралган;

- торбаүткәргечләрнең ныклыгына һәм герметиклыгына гидравлик сынау үткәрү;

- җылылык белән эшкәртелгән торбалар һәм торба үткәргеч детальләрен куллану;

- торбаүткәргечләрне һәм җайланмаларны, саклагыч өслекләр һәм электрохимик саклау чараларын кулланып, туфрак туңуыннан комплекслы яклау;

- торбаүткәргечләрнең һәм арматураның җир өсте участокларының тышкы өслеген лак-буяу материаллары белән атмосфера коррозиясеннән саклау;

- нефть һәм газ җыю һәм транспортлау объектларының барлык ачык мәйданчыкларында газ анализаторлары ярдәмендә һава мохите торышын тикшереп тору;

- җир өсте һәм җир асты суларын пычрату мөмкинлеген булдырмый торган җитештерү, җитештерү-яңгыр һәм көнкүреш агынтыларын җыю һәм бүлеп бирү системасы.

**7.3. Җир ресурсларын һәм туфрак катламын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары, шул исәптән бозылган яисә пычранган җир кишәрлекләрен һәм туфрак катламын рекультивацияләү чаралары**

Җир ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану максатларында проектта түбәндәге чаралар каралган:

- табигый ландшафтны максималь саклап, җирләрне рациональ бүлеп чыгару;

- төзелеш эшләрен катгый рәвештә бүлеп бирелгән чикләрдә башкару;

- нефть һәм нефть продуктларының агып китүен булдырмау;

- скважиналарны, торба үткәргечләрне һәм башка корылмаларны ышанычлы герметизацияләүне тәэмин итү;

- блок җиһазларын куллану;

- торбаүткәргечләрне гидравлик сынаулар белән тикшерү;

- торбаүткәргечләрнең һәм башка корылмаларның эксплуатацияләү чорында ышанычлылыгын тәэмин итү;

- эксплуатация колонналарын, нефть үткәргечләрен коррозиядән саклауны тәэмин итү;

- ремонт эшләрендә герметик аскуймалардан һәм катламлы һәм агып төшүче суларны җыю өчен савытлардан файдалану, соңыннан аларны утильләштерү;

- бетон белән капланган технологик мәйданчыкларны нефтьнең авария хәлендәге таралуына комачаулаучы бордюр белән әйләндереп алу;

- промливнев һәм производство агынты суларын технологик мәйданчыклардан чыгару, аннары аларны чистарту корылмаларына чыгару;

- махсус билгеләнгән мәйданчыкларда машиналарга һәм механизмнарга техник хезмәт күрсәтү;

планлаштыру эшләрен һәм техник рекультивацияне вакытында башкару;

- төзекләндерелә торган объектларга якын урыннарда транспорт һәм техника хәрәкәтен чикләү;

- җитештерү һәм куллану калдыкларын махсус контейнерларга җыеп, алга таба полигонга чыгару;

- бозылган җирләрне биологик рекультивацияләү;

- әйләнә-тирә мохитне саклау буенча барлык чараларны һәм кагыйдәләрне төгәл үтәү.

**7.4. Җир асты байлыкларын саклау чаралары**

Геологик мохиткә йогынтыны киметү максатында, шулай ук туфракның, төче җир асты суларының һәм җир асты байлыкларының пычрануын кисәтү өчен проектта түбәндәге чаралар каралган:

- табигый ландшафтны максималь саклап, җирләрне рациональ бүлеп чыгару;

- төзелеш эшләрен катгый рәвештә бүлеп бирелгән чикләрдә башкару;

- нефть һәм нефть продуктларының агып китүен булдырмау;

- торбаүткәргечләрне һәм башка корылмаларны ышанычлы герметизацияләүне тәэмин итү;

- торбаүткәргечләрне гидравлик сынаулар белән тикшерү;

- торбаүткәргечләрнең һәм башка корылмаларның эксплуатацияләү чорында ышанычлылыгын тәэмин итү;

- торбаүткәргечләрне коррозиядән саклауны тәэмин итү;

- промливнев һәм производство агынты суларын чистарту корылмаларына чыгарып җибәрү;

- җитештерүдә экология контроле план-графигы нигезендә сулыклардан һәм су пунктларыннан су пробаларын системалы рәвештә алу һәм анализлау;

- махсус билгеләнгән мәйданчыкларда машиналарга һәм механизмнарга техник хезмәт күрсәтү;

- планлаштыру эшләрен һәм рекультивацияне вакытында башкару;

- әйләнә-тирә мохитне саклау буенча барлык чараларны һәм кагыйдәләрне төгәл үтәү.

Күрсәтелгән чараларны үтәгәндә проектлана торган объектның геологик мохиткә йогынтысы минимумга кадәр киметелгән.

Тискәре йогынты проекттан тайпылышлар очрагында, шулай ук персонал хаталары хисабына һәм авария хәлләрендә килеп чыгарга мөмкин.

Авария хәлләре нәтиҗәсендә геологик мохитнең һәм грунт суларының пычрануын булдырмау яисә киметү максатында проектта аварияләр килеп чыгу ихтималын киметүгә юнәлдерелгән берничә технологик чишелеш каралган:

- технологик җиһазларны ачык мәйданчыкта урнаштыру, бу шартлау-янгын куркынычы булган зоналар булдыру ихтималын киметә;

- процессның һәм мохитнең коррозия активлыгының эш параметрларына туры килә торган ябу-җайга салу арматурасын һәм технологик җайланмаларны сайлау;

- процесс параметрларын автоматлаштыру чаралары, шулай ук аларны бозган очракта блоклау системасы исәбенә билгеләнгән режимда тоту;

- фланецлы кушылмаларның минималь кирәкле санын файдалану;

- торбаүткәргечләрнең ныклыгына һәм герметиклыгына гидравлик сынау үткәрү;

- җитештерү, җитештерү-яңгыр һәм көнкүреш суларын җыю һәм агызып җибәрү системасы.

Эксплуатация чорында технологик ремонт операцияләре йомык схема буенча циркуляция системалары, герметизацияләүче сальник җайланмалары, технологик Сыеклыкларның һәм башка материалларның туфракка эләгүен булдырмый торган тиз төшерелә торган торбалы тоташтырмалар кулланып башкарылырга тиеш.

Проектлана торган объектны эксплуатацияләү чорында авария хәленең килеп чыгуын булдырмау өчен түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш: корылмаларның, җиһазларның техник торышын тикшереп тору; вакытында планлы-кисәтү ремонты.

## 7.5. Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау чаралары

Территориянең үсемлекләр дөньясын саклау максатында проектта түбәндәге чаралар каралган:

- табигый ландшафтны максималь саклап, җирләрне рациональ бүлеп чыгару;
- төзелеш эшләрен катгый рәвештә бүлеп бирелгән чикләрдә башкару;
- нефть һәм нефть продуктларының агып китүен булдырмау;
- скважиналарны, торба үткәргечләрне һәм башка корылмаларны ышанычлы герметизацияләүне тәэмин итү;
- агач-куаклык үсемлекләрен проектта каралмаган рәвештә бетерүне тыю;
- төзелеш мәйданчыкларында һәм янәшәдәге территориядә үсемлекләрне яндыруны, учак ягуны, калдыкларны һәм чүп-чарны яндыруны тыю;
- махсус билгеләнгән мәйданчыкларда машиналарга һәм механизмнарга техник хезмәт күрсәтү;
- планлаштыру эшләрен һәм рекультивацияне (техник һәм биологик) вакытында башкару;
- әйләнә-тирә мохитне саклау буенча барлык чараларны һәм кагыйдәләрне төгәл үтәү.

Территориянең хайваннар дөньясын саклау максатында проектта түбәндәге чаралар каралган:

- табигый ландшафтны максималь саклап, җирләрне рациональ бүлеп чыгару;
- төзелеш эшләрен катгый рәвештә бүлеп бирелгән чикләрдә башкару;
- нефть һәм нефть продуктларының агып китүен булдырмау;
- терлекләр ачык траншеяләргә һәм чокырларга эләкмәсен өчен җир эшләренең дәвамлылыгын киметү;
- хайваннар өчен мөмкин булган урыннарда хайваннар дөньясы объектлары һәм аларның яшәү тирәлеге өчен куркыныч булган химик реагентларны һәм башка материалларны саклауны һәм куллануны тыю;
- материалларны һәм чималны киртәләнгән урыннарда бетонланган һәм җимерелгән мәйданчыкларда гына саклау;

- территориянең төзелеш һәм коммуналь калдыклар белән чүпләнүен булдырмау.

Проектлана торган эшләрне штат режимында башкарганда, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының санына һәм төр составына йогынты локаль характерда булачак. Районның флора һәм фаунасы составында сизелерлек үзгәрешләр көтелми.

Проектлана торган объектларны нормаль режимда эксплуатацияләү янәшәдәге территориянең үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына мөмкин булган йогынты ясаячак.

**7.6. Куркыныч калдыкларны җыю, алардан файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру чаралары**

Табигый мохитне (үсемлекләрне, туфракны, җир асты суларын һәм җир асты байлыкларын) СМР калдыклары белән пычранудан саклауны тәэмин итү буенча экологик таләпләрне үтәү өчен җитештерү һәм коммуналь калдыклар белән эш итү системасы оештырыла. Система түбәндәгеләрне күздә тота:

- СМР чорында барлыкка килә торган инерт төзелеш материаллары калдыкларыннан алдагы технологик операцияләрдә файдалану, бу исә калдыкларны иң аз күмүне һәм табигать ресурсларын саклауны тәэмин итә;
- калдыкларны рөхсәтсез урнаштыруны һәм территорияләрне чүп-чардан арындыруны булдырмау өчен калдыкларны урнаштыру һәм эшкәртү урыннарына даими рәвештә чыгару;
- төзелеш эшләре башланганчы калдыкларны махсуслаштырылган оешмаларга тапшыру турында шартнамәләр төзү;
- барлыкка килә торган калдыкларны эшкәртү предприятиесенә урнаштыруны, шулай ук күмү өчен полигонга чыгаруны тәэмин итү өчен аларның төрләре һәм класслары буенча аерым җыюны оештыру;
- эшләр башкарылган участоктан калдыкларны чыгару ешлыгын үтәү, шулай ук аларны эшкәртү яисә күмү өчен башка объектларга тапшыру шартларын үтәү;
- эшләр башкару участогында калдыкларны табигатьне саклау законнары таләпләре нигезендә вакытлыча саклау шартларын үтәү;
- идарәнең җиһазландырылган стационар җитештерү участокларында үзәкләштерелгән җыю өчен алып чыгу хисабына җитештерү һәм коммуналь калдыкларны төзелеш мәйданчыкларында кыска вакытлы саклау;
- калдыкларны транспортлауга карата санитар-экологик таләпләрне үтәү.

**7.7. Капиталь төзелеш объектында мөмкин булган авария хәлләре килеп чыгуны һәм аларның регион экосистемасына йогынтысы нәтиҗәләрен минимальләштерү чаралары**

«Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелеш объектлары куркыныч объектлар категориясенә керми.

Торбаүткәргечләрне эксплуатацияләү барышында аварияләр торбаүткәргечләрнең коррозиядән җимерелүе, төрле механизмнарның механик

зарарлануы, торбаүткәргечләрне ремонтлаганда ут эшләрен башкарганда килеп чыга.

Монтаж һәм ремонт эшләрен башкарганда җибәрелгән хаталар торбаүткәргечне эксплуатацияләү процессында нефтьнең агып китүенә китерергә мөмкин. Куркыныч участокларда мөмкин булган аварияләр һәм инцидентлар килеп чыгуның башлангыч вакыйгалары (сәбәпләре) булырга мөмкин:

1) технологик җайланманың механик тузуы;

2) фланцларның тыгызлануы яисә конструкцияләренең, прокладка материалының ялгыш сайланган типлары, беркетү болтларын җитәрлек тартмау яисә тигезсез тартмау, беркетү эшләнмәләренең тулы комплекты булмау һ.б. нәтиҗәсендә фланцевый кушылмаларның тыгызлыгы яисә аларның таркалуы;

3) технологик җайланма диварларының тутыгуы;

4) технологик системалар элементларының үтә алмавы;

5) технологик процесс параметрларын җайга салу системаларының төзексезлеге;

6) җайга салу һәм ябу арматурасы тыгызлауларының сафтан чыгуы;

7) технологик җайланма материалының эксплуатацияләү шартларына туры килмәве;

8) аппаратураның яисә торбаүткәргечләрнең механик зарарлануы;

9) җиһазларны монтажлаганда һәм ремонтлаганда җибәрелгән хаталар;

10) хезмәт күрсәтүче персонал гамәлләре аркасында килеп чыккан эксплуатация хаталары;

11) террорчылык актлары;

12) табигать факторларының йогынтысы.

Санап үтелгән башлангыч вакыйгаларны тагын да эрерәк итеп өч төркемгә төркемләргә мөмкин:

- технологик факторга бәйле вакыйгалар;
- табигать йогынтысына бәйле вакыйгалар;
- кеше факторы белән бәйле вакыйгалар.

Төп җиһазның (суүткәргечнең) физик тузуы нигездә торбаүткәргеч стеналарына йөкләнешнең цикллы тәэсире белән бәйле. Бу яктан торбаүткәргечләрнең насос станцияләренә турыдан-туры тоташкан участоклары аеруча зәгыйфь була, алар суырту режимы үзгәрү һәм шул вакытта гидравлик дулкыннар барлыкка килү нәтиҗәсендә торбаүткәргечләргә циклик йөкләнеш чыганагы булып торалар.

Төрле табигый факторларның йогынтысы шулай ук җиһазларның герметиклыгын киметүгә сәбәп булырга мөмкин. Шулай итеп аппаратлар металлында җәрәхәтле коррозияләр булганда югары температура деформацияләренә китерә торган аномаль түбән температуралар технологик җиһазларның нәзберек җимерелүенә һәм, нәтиҗә буларак, куркыныч матдәләрнең әйләнә-тирәгә бүленеп чыгуына китерергә мөмкин.

Кеше факторы китереп чыгарган технологик җиһазларның герметиксызлануы нигездә ремонт эшләрен башкарганда җибәрелгән хаталар белән аңлатыла, бу исә еш кына фланец кушылмаларының тыгызлыгы булмау, насосларның тыгызлануы һәм

ябылу арматурасы аша куркыныч матдәләрнең агып чыгуына китерергә мөмкин.

**7.8. Проектлана торган объектта гадәттән тыш хәлләр куркынычын киметүгә юнәлдерелгән чаралар**

Проектлана торган объектта куркынычны һәм зарарлылыкны киметү максатында проектта түбәндәге чаралар карала:

- технологик процесс максималь герметизацияләнгән;
- басым астында эшли торган савытлар саклагыч клапаннар белән җиһазландырыла;
- биеклектә урнашкан бикләү арматурасына һәм контроль-үлчәү приборларына (сепараторларда, савытларда һәм башка аппаратларда һәм корылмаларда) хезмәт күрсәтү өчен киртәле баскычлар һәм хезмәт күрсәтү мәйданчыклары каралган;
- төп технологик операцияләр белән идарә итү даими хезмәт күрсәтүче персоналдан башка автоматлаштыру чаралары ярдәмендә башкарыла;
- объект территориясендә кешегә яна торган куркыныч турында тыю һәм кисәтү плакатлары һәм билгеләре эленергә тиеш;
- җайланма җиһазларына Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Нефть һәм газ сәнәгатендә куркынычсызлык кагыйдәләре» сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсе федераль нормаларын һәм кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 15 декабрендәге 534 номерлы боерыгы белән танышкан квалификацияле персонал хезмәт күрсәтергә тиеш;
- җиһазларны, арматураны һәм торбаүткәргечләрне сайлау эш басымыннан, температурадан, тирәлекнең коррозиялелегеннән һ.б. чыгып башкарыла;
- аппаратларны һәм торбаүткәргечләрне дренажлау ябык системага (дренаж сыешлыгына) башкарыла;
- торбаларны тоташтыру эретеп ябыштырганда башкарыла, фланцев тоташтырулар арматураны һәм җиһазларны тоташтыру өчен генә урнаштырыла;
- хезмәт күрсәтүче персоналның иминлеген тәэмин итү өчен җиһазларның металл өлешләрен җиргә утырту күздә тотыла.

Объектта җитештерү процессларының куркынычсызлыгы шулай ук норматив документация таләпләрен канәгатьләндерә торган һәм имгәнүләр һәм һөнәри авырулар чыганагы булмаган җитештерү җиһазларын куллану исәбенә дә тәэмин ителә.

**7.9. Җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, туплау, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру гамәлләре**

Вакытлыча саклау (туплау) аларның барлыкка килү чыганаклары урыннарында, ягъни бүленгән участок чикләрендә төзелеш объектына турыдан-туры якын территорияләрдә Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган СанПиН 2.1.3684-21 «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм халыкны эчә торган су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать урыннарын эксплуатацияләүгә,

санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр» санитария нормалары һәм кагыйдәләренең санитар-экологик таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

Төзелеш эшләрен башкару чорында калдыкларны туплау (вакытлыча туплау) урыннары төзелеш мәйданчыкларында карала һәм эшләрне башкару проектында билгеләнә.

СМР үткәрү алдыннан төзелеш мәйданчыгында эшчеләрнең тормыш эшчәнлеге һәм хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән калдыкларны җыю өчен металл контейнерлар урнаштырыла.

Предприятиедә калдыкларны җыю һәм вакытлыча саклау өчен үзәкләштерелгән урыннар оештырылган. Калдыклар тупланган саен махсуслаштырылган объектларга урнаштыру өчен тапшырыла.

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 24.7 статьясындагы 4 пункты нигезендә ККК милекчеләре каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә эшчәнлек зонасында каты коммуналь калдыклар барлыкка килә һәм аларны туплау урыннары урнашкан региональ оператор белән килешү төзергә тиеш.

Проектлана торган объект ККК белән эш итү буенча региональ оператор эшчәнлегенең көнчыгыш зонасында урнашкан, проектлау вакытында региональ оператор булып «Гринта» ҖЧҖ тора.

Каты көнкүреш калдыкларына тиңләштерелгән калдыкларны Түбән Кама районында, Шәңгәлче авыл җирлегендә Сарсаз-Блин авылына якын урында урнашкан калдыклар белән эш итү комплексына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 13.03.2018 ел, № 149 карары белән расланган Татарстан Республикасы калдыклары белән эш итү өлкәсендә территориаль планлаштыру схемасы нигезендә) чыгару күздә тотыла.

Сәнәгать калдыклары милекчеләре сәнәгать калдыклары белән эш итүгә лицензияләре булган тиешле оешмалар белән килешүләр төзи.

«Экология» илкүләм проекты составында гы «I һәм II класслы калдыклар белән эш итү өчен инфраструктура» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында «Федераль экология операторы» ФДУП Россия Федерациясе территориясендә I-II класслы калдыклар белән эш итү буенча федераль оператор итеп билгеләнгән.

Калдыкларның төрләре, саны, токсиклыгы, җыю, туплау һәм утильләштерү системасы турындагы мәгълүматлар «Татнефть» ГАҖ структур бүлекчәләрендә калдыклар белән эш итү буенча РД нигезендә кабул ителә.

Калдыклар белән эш итүнең күрсәтелгән механизмы әйләнә-тирә мохит компонентларын җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычрату мөмкинлеген минимумга җиткерә.

Материалны туплаганда, ташыганда һәм транспортлаганда Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Көкләрне төяү-бушату һәм урнаштырганда хезмәтне саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 октябрендәге 753н номерлы боерыгы таләпләре үтәлергә тиеш.

**8. Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

**8.1. Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы түбәндәгеләргә бәйле:**

«Хәвефле җитештерү объектларының сәнәгать иминлеге турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә хәвефле җитештерү объектларына – куркыныч категориягә керә, куркыныч категориягә куркыныч матдәләр (янучан, оксидлашучан, янучан, шартлаучан һәм агулы) табыла, кулланыла, эшкәртелә, хасил ителә, саклана, күчерелә һәм юкка чыгарыла торган объектлар керә.

Алабуга нефть чыганагы скважиналарыннан иярчен газ булган су-нефть эмульсиясе проектлана торган корылмаларда әйләнә торган куркыныч матдә булып тора.

Нефть янгын чыгу һәм шартлау куркынычы югары булган углеводородлар катнашмасы булып тора.

СССР Дәүләт стандартының 10.03.1976 ел, № 579 карары белән расланган һәм гамәлгә кертелгән ГОСТ 12.1.007-76 «Хезмәт куркынычсызлыгы стандартлары системасы. Зарарлы матдәләр. Куркынычсызлыкның классификациясе һәм гомуми таләпләре» дәүләтара стандарты нигезендә куркыныч матдәнең токсик куркынычлык классы – 3.

Проектлана торган «Алабуга нефть ятмасының промысел (промыселара) торба үткәргечләре системасы («Прикамнефть» НГЧИ) А43-01519-0915 объекты гамәлдәге куркыныч җитештерү объектына керә, II куркынычлык классы.

Нефть куркынычлыкның 3 классы – уртача куркынычлы матдә булып тора. Янучанлыкның түбәнге чиге – һавадагы күләм буенча 2,9%, югары чиге – 15 %. СССР Дәүләт стандартының 1988 елның 29 сентябрендәге 3388 номерлы карары белән расланган һәм гамәлгә кертелгән ГОСТ 12.1.005-88 «Хезмәт куркынычсызлыгы стандартлары системасы. Эш зонасы һавасына гомуми санитария-гигиена таләпләре» дәүләтара стандарты нигезендә нефть аэрозоленең эш зонасы һавасындагы ПДК күләме 10 мг/м3 артык түгел; углеродка күчереп исәпләгәндә җиңел углеводородлар буенча концентрация 300 артмый Кешегә ясала торган йогынтысы: күкерт водороды булган нефть парлары наркотик, агулаучы һәм буу характерындагы йогынты ясый. Үзәк нерв системасына, сулыш органнарына, тирегә тәэсир итә.

Нефть газы – 3 класслы куркыныч матдә – уртача дәрәҗәдә куркыныч матдә. Янучанлыкның түбәнге чиге – һавадагы күләм буенча 2,9%, югары чиге – 15 %. СССР Дәүләт стандартының 1988 елның 29 сентябрендәге 3388-300 номерлы карары белән расланган һәм гамәлгә кертелгән ГОСТ 12.1.005-88 «Хезмәт куркынычсызлыгы стандартлары системасы. Эш зонасы һавасына гомуми санитария-гигиена таләпләре» дәүләтара стандарты нигезендә углеводородлар буенча эш

зонасы һавасындагы мг/м3 ПДК күләме 3 (углеводородлар белән катнашмада күкертле водород); 10 (күкертле водород буенча). Кешегә наркотик, агулы һәм буу характерындагы йогынты ясый. Үзәк нерв системасына, сулыш органнарына, тирегә тәэсир итә. Сероводород – көчле агу, сулыш тукталудан үлемгә китерә.

**8.2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 15.01.2024 ел, № 165/ТЗ-3-5 хаты нигезендә проектлана торган объект өчен «Гражданнар оборонасы чаралары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге» бүлеген эшләү зарур (башлангыч мәгълүматлар һәм таләпләр бирелгән).**

Проект документациясен эшләгәндә түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

Инженер-геологик эзләнүләр нәтиҗәләре. 13194-ИГИ хисабы (О кушымтасы, 13194-ППТ-МО-Р4 бүлеге) нигезендә территориянең өске һәм тирән грунт массивларының трасса полосалары буенча тотрыклылыгына тискәре йогынты ясарга мөмкин булган куркыныч табигый һәм техноген процесслар һәм күренешләр (эрозия, шуышулар, суффозия, сөзәк процесслар һ.б.) (эрозия, тайганаклар, суффозия, карст һ. б.) ачыкланмаган. Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 16 декабрендәге 970/пр номерлы боерыгы белән расланган СП 22.13330.2016 «Биналар һәм корылмалар нигезләре. СНиП 2.02.01-83 актуальләштерелгән редакциясе*» кагыйдәләр җыелмасы нигезендә карст-суффозия ягыннан төзелеш участогының куркыныч категориясе буенча территория – куркыныч түгел. Факторлар җыелмасы буенча, территориянең карстка тотрыклылыгы категориясе буенча Россия Дәүләт төзелеш күзәтчелегенең 03.11.1999 ел, №5-11/140 хаты белән расланган «Төзелеш өчен инженер-геологик эзләнүләр» СП 11-105-97 кагыйдәләр җыелмасы нигезендә объект VI тотрыклылык категориясе территориясендә урнашкан һәм биналарны, корылмаларны төзү карстка каршы чараларны кулланмыйча гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Инженер-гидрометерологик тикшеренүләр нәтиҗәләре. 13194-ИГМИ хисабы (О кушымтасы, 13194-ППТ-МО-Р4 бүлеге) нигезендә төзелеш мәйданчыгы су саклау зоналарыннан һәм яр буе яклау полосаларыннан читтә урнаша, су киртәләре белән кисешүләр юк, мәйданчык су басу зонасыннан читтә урнаша.

**8.3. Проектлана торган объект В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ булып тора. Ул гражданнар оборонасы буенча икенче категориягә кертелгән һәм гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә кертелгән территорияләрдән (Түбән Кама шәһәре) читтә урнашкан.**

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 15.01.2024 ел, №165/ТЗ-3-5 хаты нигезендә:

- проектлана торган объект гражданнар оборонасы буенча категорияләнмәгән булып тора;
- проектлана торган объект гражданнар оборонасы буенча I төркемгә кертелгән Түбән Кама шәһәреннән якынча 3 км ераклыкта урнашкан;
- проектлана торган объект «Түбән Кама нефтехим» ГАҖ (этилен оксиды,

аммиак, хлор) тарафыннан химик зарарлану зонасына эләгә;

- проектлана торган объект җимерелү, радиоактив зарарлану һәм су басу ихтималы булган зоналарга эләкми;

- объектта гражданнар оборонасының саклау корылмаларын төзү таләп ителми.

Проектлана торган объектны гражданнар оборонасы категориясенә кертүне Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт икътисадындагы роленә яисә халыкның иминлегенә йогынтысына карап, оешмаларны гражданнар оборонасы категорияләренә кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 16 августындагы 804 ДСП номерлы карары таләпләренә туры китереп үткәрергә.

«Гражданнар оборонасы чаралары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге» бүлеген эшләүне Росстандартның 12.01.2023 ел, № 10-ст боерыгы белән расланган һәм гамәлгә кертелгән ГОСТ Р 22.2.13-2023 «Гадәттән тыш хәлләрдә куркынычсызлык. Гражданнар оборонасы буенча чаралар, капиталь төзелеш объектларын проектлаганда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеген эшләү тәртибе» илкүләм стандарты, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чараларын проектлау нормалары һәм кагыйдәләре булган башка норматив-техник документларга катгый нигезләнеп алып барырга.

ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2025 елның 10 июнендәге 741/о номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында урнашкан «Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү – 1 чират» объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне ызанлау проекты**

| Бүлек номеры | Билгеләнеше | Атамасы | Иск. |
|---|---|---|---|
| 1 | 13194-ППТ-ОЧ-Р1 | 1 бүлек: Территорияне планлаштыру проекты. | |
| | | График өлеше | |
| 2 | 13194-ППТ-ОЧ-Р2 | 2 бүлек: Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | |
| 3 | 13194-ППТ-МО-Р3 | 3 бүлек: Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | График өлеше | |
| 4 | 13194-ППТ-МО-Р4 | 4 бүлек: Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | Аңлатма язуы | |
| 5 | 13194-ПМТ-ОЧ-Р5 | 5 бүлек: Территорияне ызанлау проекты. | |
| | | График өлеше | |
| 6 | 13194-ПМТ-ОЧ-Р6 | 6 бүлек: Территорияне ызанлау проекты. | |
| | | Текст өлеше | |
| 7 | 13194-ПМТ-МО-Р7 | 7 бүлек: Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | График өлеше | |
| 8 | 13194-ПМТ-МО-Р8 | 8 бүлек: Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. | Китерелми |
| | | Аңлатма язуы | |

**«Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү – 1 чират «объекты буенча территорияне планлаштыру документлары**

**Территорияне ызанлау проекты**

**5 бүлек: Территорияне ызанлау проекты. График өлеше**

«Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү -1 чират» объекты территориясен ызанлау проекты составында барлыкка килә торган җир кишәрлекләре юк, шуңа бәйле рәвештә территорияне ызанлау сызымы эшләнмәгән.

## 6 бүлек: Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше

### Кулланылган кыскартулар исемлеге

ЕЗ – Җирдән бердәм файдалану

### 1. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләре исемлеге

«Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү -1 чират» объекты территориясен ызанлау проекты составында барлыкка килүче җир кишәрлекләре юк.

«Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү -1 чират» объектын төзү һәм алга таба эксплуатацияләү кысаларында вакытлыча (төзелеш чорына) җир бүлеп бирү оештыру планлаштырыла.

Җирләрне вакытлыча биләп тору төзелеш чорына кадастр исәбенә куелмыйча формалаштырыла. Линия объектын гавами сервитут шартларында урнаштыру өчен җирләрне вакытлыча файдалануга бирү каралган.

Чикләрендә объектны гавами сервитут шартларында урнаштыру күздә тотыла торган җир кишәрлекләре исемлеге 1 нче таблицада күрсәтелгән.

**1 нче таблица – Чикләрендә объектны гавами сервитут шартларында урнаштыру күздә тотыла торган җир кишәрлекләре исемлеге**

| Булган җир кишәрлегенең кадастр номеры/(бер өлеше) файдалануга тапшыру өчен каралган җирдән (кадастр кварталының) бердәм файдалану номеры | Күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр | Рөхсәт ителгән файдалану төре | Булган җир кишәрлегенең урнашу урыны (җир кишәрлегенең адресы) |
|---|---|---|---|
| 16:30:040201:370 | юк | Җир асты байлыкларыннан файдалану | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, «Кама шәһәре шәһәре» МБ |
| 16:30:040201:383 | юк | Авыл хуҗалыгында файдалану өчен | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, «Кама шәһәре шәһәре» МБ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16:30:040201 | юк | - | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы |
| 16:30:000000:3680 | юк | Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Прости авыл җирлеге |
| 16:30:040201:397 | юк | Җир асты байлыкларыннан файдалану | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Прости авыл җирлеге |
| 16:30:040201:412 | юк | авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Прости авыл җирлеге |
| 16:30:040201:414 | юк | авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Прости авыл җирлеге |
| 16:30:040201:390 | юк | Җир асты байлыкларыннан файдалану | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Прости авыл җирлеге |
| 16:30:040201:416 | юк | авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Прости авыл җирлеге |
| 16:30:040201:48 ЕЗ 16:30:000000:274 | юк | авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы |
| 16:30:000000:1594 | юк | авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы |
| 16:30:040302 | юк | - | Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы |

**2. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми)**

«Алабуга нефть ятмасын төзекләндерү -1 чират» объекты территориясен ызанлау проекты составында барлыкка килүче җир кишәрлекләре юк.

**3. Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында белешмәләр (китерелми)**

Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла

торган координаталар системасында мондый чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеген үз эченә алган белешмәләр. Территориаль зоналар өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләренең характерлы нокталары координаталары чикләрнең характерлы нокталары координаталарын төгәл билгеләү таләпләре нигезендә билгеләнә, алар «Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләренең борылыш нокталары координаталары исемлеге» дигән 2 нче таблицада китерелде.

**2 нче таблица. Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләренең борылыш нокталары координаталары исемлеге (китерелми)**

**4. Барлыкка китерелә торган җир кишәрлекләреннән территорияне планлаштыру проекты нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре**

Территорияне ызанлау проектында җир кишәрлеге булдыру каралмаган.